КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 июль г.Казань № 521

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга табиб рецептлары буенча өч яшькә кадәр балаларны махсус һәм сөт ризыклары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2016 ел, 10 ноябрь, 838 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә урнашкан медицина оешмалары каршында сөт тарату пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша табиб рецептлары буенча өч яшькә кадәр балаларны махсус һәм сөт ризыклары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарга үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга табиб рецептлары буенча өч яшькә кадәр балаларны махсус һәм сөт ризыклары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2016 ел, 10 ноябрь, 838 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә урнашкан медицина оешмалары каршында сөт тарату пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша табиб рецептлары буенча өч яшькә кадәр балаларны махсус һәм сөт ризыклары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«ВИЧ-инфекцияле аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекцияле балалар» юлында «38,78» саннарын «77,56» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карар 2017 елның 1 августыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин